РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12 октябрь 2016 ел № 1- 22

«Җир салымы турында»

Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1 Статья. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нормалары нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә җир салымы (алга таба - салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2 Статья. Салым ставкалары

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,1%-ы;

2) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,1%ы;

3) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составына кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы зоналары составындагы җирләргә карата кадастр бәясенең 0,3%ы;

4) торак пунктлар чикләреннән тыш урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 1,5%ы: сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, мәгълүмат җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона җирләре, оешмалар һәм учреждениеләргә караган башка махсус билгеләнештәге җирләр;

5) башка җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 1,5%ы.

3 Статья. Хисап чоры

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы танылa дип билгеләргә.

4 Статья. Салым ташламалары

1. Россия Федерациясе Салым кодексының 389 статьясында каралган очраклардан тыш, граждан күмүләре өчен авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә карата оешмаларны, учреждениеләрне җир салымы түләүдән азат итәргә.

2. Җир салымының түбән ставкасын билгеләргә:

2.1. дәүләт хакимияте һәм идарә органнарының, җирле үзидарә органнарының, казна учреждениеләренең, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Буа муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган бюджет һәм автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,847% күләмендә;

2.2. сәнәгать җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге (торак пунктлардан тыш) гомуми файдаланудагы 1 - 3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,05% күләмендә.

5 Статья. Салым буенча салым һәм аванс түләүләрен түләү тәртибе һәм сроклары

1. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү салым чоры булып торучы елның 1 гыйнварына, 5 майга, 5 августка, 5 ноябрьгә нисбәттә җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым түләү срогы үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февралендә билгеләнә.

6 Статья. Салым түләүчеләр тарафыннан салым салына торган базаны киметүгә хокукны раслый торган документлар тапшыру тәртибе һәм сроклары

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслый торган документлар салым түләүчеләр тарафыннан салым салу объекты буларак танылa торган җир кишәрлегенең урнашкан урыны буенча салым органына узган салым чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр тапшырыла.

7 Статья. Җир кишәрлекләренең кадастр хакын салым түләүчеләр игътибарына җиткерү тәртибе

Җир кишәрлекләренең кадастр бәясе җирләрне дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү нәтиҗәләре буенча, календарь елның 1 гыйнварына торышы буенча, агымдагы елның 1 мартыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә салым түләүчеләр игътибарына җиткерелергә тиеш.

8 Статья. Әлеге карарның үз көченә керүе

1. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан һәм рәсми игълан ителгән көненнән соң бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, җирлектә махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштыру, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән үз көченә керә.

2. Әлеге карар үз көченә кергәч, Адав-Толымбай авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 2014 елның 14 ноябрендәге 2-52 номерлы карарын (тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Хөсниева